**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның 8 сентябреннән № 26-207

2021 елда «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны, спортны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы М. А. Магомедованың 2021 елда «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны, спортны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар турындагы мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы М. А. Магомедованың 2021 елда «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны, спортны үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар турындагы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә:

- 2022 елда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче район халкының санын - 54,3 %ка кадәр, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә даими рәвештә шөгыльләнүче балаларны һәм яшүсмерләрне - 70,2 %ка кадәр арттырырга;

– спортчыларның әзерлеген яхшыртырга, тренер-укытучыларның квалификациясен күтәрергә, физик культура өлкәсендә республика семинарларында катнашырга;

- Республика ярышларында күрсәткечләрне яхшыртырга, ягъни тренировка дәресләренең яңа формаларын һәм методларын кулланырга;

- мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында адаптив физик культура һәм спортны үстерү буенча эшне камилләштерергә;

3. Татарстан Республикасы Яңа чишмә муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә сынаулар (тестлар) төрләрен, нормативларны, белем дәрәҗәсен бәяләүгә карата таләпләрне үтәү буенча тест үзәгенә:

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын кертүне дәвам итәргә;

- 2022 елда бик яхшы билгеләренә башкаручылар санны 7%ка кадәр арттыруга ирешергә

4. «Татмедиа» ААҖ филиалы директорына «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасына халыкның спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше белән кызыксынуын арттырырга, ГТО ВФСК пропагандасына, район халкына спорт чаралары, программалар, проектлар, акцияләр, спорт объектлары һәм башка актуаль мәгълүматлар турында мәгълүмат бирүне дәвам итәргә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов